**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об учреждении Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 июля 2020 года № УП-453 «Об учреждении Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 28 июня 2022 года № УП-441) следующие изменения:

а) в Положении о Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии:

в пункте 2 слова «Президентом Республики Татарстан» заменить словами «Раисом Республики Татарстан»;

в пункте 6:

слова «Президента Республики Татарстан» заменить словами «Раиса Республики Татарстан»;

слова «об учреждении» заменить словами «о присуждении»;

в пункте 11 слова «Президента Республики Татарстан» заменить словами «Раиса Республики Татарстан»;

в пункте 13 слова «Президентом Республики Татарстан» заменить словами «Раисом Республики Татарстан»;

б) в Положении о Комитете по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии:

в пункте 1 слова «Президенту Республики Татарстан» заменить словами «Раису Республики Татарстан»;

в пункте 2 слова «Президентом Республики Татарстан» заменить словами «Раисом Республики Татарстан»;

в подпункте «в» пункта 3 слова «Президенту Республики Татарстан» заменить словами «Раису Республики Татарстан»;

в пункте 9 слова «с правом совещательного голоса» исключить;

пункт 10 дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае невозможности присутствия членов Комитета на заседании или участия членов Комитета в заседании дистанционно с использованием видео-конференц-связи их мнение может быть получено в письменной форме и учитывается при принятии решения.»;

в пункте 11 слова «присутствующих на» заменить словами «участвующих в»;

в) в составе Комитета по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии (далее – Комитет):

вывести из состава Комитета М.Х. Салахова;

ввести в состав Комитета:

Минниханова Рифката Нургалиевича – президента Академии наук Республики Татарстан, утвердив его заместителем председателя Комитета (по согласованию);

Зиганшина Марата Ахмедовича – директора Химического института им. А.М. Бутлерова федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет», члена-корреспондента Академии наук Республики Татарстан (по согласованию);

Карасика Андрея Анатольевича – руководителя Института органической и физической химии им. А.Е. Арбузова – обособленного структурного подразделения Федерального исследовательского центра «Казанский научный центр Российской академии наук», члена-корреспондента Российской академии наук (по согласованию);

Терентьева Александра Олеговича – исполняющего обязанности директора федерального государственного бюджетного учреждения науки Института органической химии им. Н.Д. Зелинского Российской академии наук, члена-корреспондента Российской академии наук (по согласованию);

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

И.Л. Федюшкина – «директор федерального государственного бюджетного учреждения науки Института металлоорганической химии им. Г.А. Разуваева Российской академии наук, академик Российской академии наук (по согласованию)»;

М.П. Егорова – «заведующий лабораторией химии карбенов и других нестабильных молекул федерального государственного бюджетного учреждения науки Института органической химии им. Н.Д. Зелинского Российской академии наук, академик-секретарь Отделения химии и наук о материалах Российской академии наук, академик Российской академии наук (по согласованию)»;

г) приложение № 5 изложить в следующей редакции:

«Приложение № 5
к Указу Президента
Республики Татарстан
от 25 июля 2020 года
№ УП-453

**Описание и образец бланка диплома лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии**

Бланк диплома лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии печатается на мелованной бумаге плотностью 100 г/кв.м, которая содержит 25% хлопкового волокна, без оптического отбеливателя.

Бланк диплома представляет собой лист формата А4 (210 мм × 297 мм), расположенный вертикально, цветовой фон которого белый.

По центру бланка диплома располагается выполненная черным цветом (шрифт Times New Roman Italic, кегль 14 п.) надпись на трех языках – татарском, русском и английском:

*«ДИПЛОМ*
*лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова*
*за выдающийся вклад в области органической химии*

*Указом Раиса Республики Татарстан*
*Международная премия имени В.В. Марковникова _____ года*
*присуждена*
*__________________________________________________».*

Ниже надписи располагается подпись, выполненная на трех языках – татарском, русском и английском, которая состоит из слов «Раис Республики Татарстан», инициала имени, инициала отчества и фамилии Раиса Республики Татарстан.

*Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен*
*В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты*
*ДИПЛОМЫ*

*Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә*
*_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия*
*__________________________________________________*
*бирелде*

*****

*ДИПЛОМ*
*лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова*
*за выдающийся вклад в области органической химии*

*Указом Раиса Республики Татарстан*
*Международная премия имени В.В. Марковникова _____ года*
*присуждена*
*__________________________________________________*

*****

20___ INTERNATIONAL VLADIMIR MARKOVNIKOV AWARD
CERTIFICATE

*is presented to*

______________________________________________

*for outstanding contributions in the field of organic chemistry*

*by the Decree of the Rais of the Republic of Tatarstan*

| | |
|---|---|
| *Татарстан Республикасы Рәисе* | *Р.Н. Миңнеханов* |
| *Раис Республики Татарстан* | *Р.Н. Минниханов* |
| *Rais of the Republic of Tatarstan* | *Rustam Minnikhanov* |

___________».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
10 февраля 2024 года
№ 104

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында» 2020 елның 25 июлендәге ПУ-453 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 28 июнендәге ПУ-441 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия турында нигезләмәдә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

«Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

«гамәлгә кую турында» сүзләрен «бирү турында» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмәдә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9 пункттагы «утырышта тавыш бирү хокукы булган» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комитет әгъзаларының утырышта булулары яисә Комитет әгъзаларының видео-конференц-элемтә файдаланып утырышта читтән торып катнашулары мөмкин булмаган очракта, аларның фикере язма рәвештә бирелергә мөмкин һәм карар кабул ителгәндә исәпкә алына.»;

11 пунктта «булган» сүзен «катнашучы» сүзенә алмаштырырга;

в) Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан М.Х. Сәлаховны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Комитет рәисе урынбасары итеп раслап, Миңнеханов Рифкать Нургали улын – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президентын (килешү буенча);

Җиһаншин Марат Әхмәт улын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты директорын, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасын (килешү буенча);

Карасик Андрей Анатольевичны – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге аерымланган структур бүлекчәсе – А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты җитәкчесен, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасын (килешү буенча);

Терентьев Александр Олеговичны – Россия фәннәр академиясенең Н.Д. Зелинский исемендәге Органик химия институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручыны, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасын (килешү буенча);

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Л. Федюшкинның – «Россия фәннәр академиясенең Г.А. Разуваев исемендәге Металл-органик химия институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча);

М.П. Егоровның – «Россия фәннәр академиясенең Н.Д. Зелинский исемендәге Органик химия институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең карбеннар химиясе һәм башка тотрыклы булмаган молекулалар лабораториясе мөдире, Россия фәннәр академиясенең Химия һәм материаллар турында фәннәр бүлекчәсе академигы-секретаре, Россия фәннәр академиясе академигы (килешү буенча)»;

г) 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның 25 июлендәге
ПУ-453 номерлы Указына
5 нче кушымта

**Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен
В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты дипломы
бланкы тасвирламасы һәм үрнәге**

Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты дипломы бланкы тыгызлыгы 100 г/кв.м булган, 25% мамык җепселле, оптик агартылмаган югары сыйфатлы кәгазьгә басыла.

Диплом бланкы А4 (210 мм × 297 мм) форматтагы, вертикаль урнаштырылган кәгазь бите рәвешендә була, фоны ак төстә.

Диплом бланкының уртасында өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә (Times New Roman Italic шрифты белән, 14 п. кегльдә) кара төстәге язма урнаштырылган:

*«Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен
В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә
_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия
_______________________________________________бирелде».*

Язмадан астарак өч телдә – татар, рус һәм инглиз телләрендә имза урнаштырылган, ул «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләреннән, Татарстан Республикасы Рәисенең исеме инициалыннан, атасының исеме инициалыннан һәм фамилиясеннән тора.

*Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен
В.В. Марковников исемендәге халыкара премия лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә
_____ елда В.В. Марковников исемендәге халыкара премия*

_______________________________________________

*бирелде*

*****

***ДИПЛОМ***

*лауреата Международной премии имени В.В. Марковникова*
*за выдающийся вклад в области органической химии*

*Указом Раиса Республики Татарстан*
*Международная премия имени В.В. Марковникова ______ года*
*присуждена*

______________________________________________________

*****

20___ INTERNATIONAL VLADIMIR MARKOVNIKOV AWARD
CERTIFICATE

*is presented to*

______________________________________________________

*for outstanding contributions in the field of organic chemistry*

*by the Decree of the Rais of the Republic of Tatarstan*

| | |
|---|---|
| *Татарстан Республикасы Рәисе* | *Р.Н. Миңнеханов* |
| *Раис Республики Татарстан* | *Р.Н. Минниханов* |
| *Rais of the Republic of Tatarstan* | *Rustam Minnikhanov* |

_________».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы Рәисе** | **Р.Н. Миңнеханов** |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 10 февраль
№ 104